## КЕРТТЕМ СИНЕ ҖЫРЛАРГА

Айрат Нәбиев көе

(Гөлназ Биктимирова репертуарыннан)

Капламасын гомер күген
Һич кайчан кара болыт,
Яшә минем яннарымда
Саклаучы фәрештәм булып.

*Кушымта:*
Фәрештәм дип, алиһәм дип,
Керттем сине җырларга,
Гомерләрнең кадерен белеп
Җырларга да, җырларга!

Ходай безне бер-беребезгә
Яраткан бер көн белеп,
Яшәекче гомерләрнең
Рәхәтен, кадерен белеп.

*Кушымта.*

Син барында һич куркытмый
Язмышның ачы җиле.
Яклаучым син, саклаучым син -
Гомерлек бәхетем минем!

*Кушымта.*